Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

КАРАР

31 июль, 2024 ел

№ 20

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставы нигезендә Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген, гомуми булмаган файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә юл эшчәнлеге.

2. Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Зур Сәрдек авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый һәм финанс мәсьәләләре буенча җирлек Советы комиссиясенә йөкләргә.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Фаттахов

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727